**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 ноябрь № 847

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы, 2015 ел, 6 май, 325 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

8 таблицаның 4 графасында:

«Акылы зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йорты» һәм «Физик кимчелекләре булган балалар өчен балалар интернат йорты» юлларында «0,303» саннарын «0,349» саннарына алмаштырырга;

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге» юлында «0,939», «0,344»,«0,1806» саннарын тиешенчә «1,039», «0,380»,«0,2000» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның көче 2015 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\847.docx